ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

18.09.2017 — с. Набережные Моркваши — 19

## Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 елдан № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Яр буе Моркваашы авыл җирлеге Уставының 11 ст.нигезендә,

Карар бирәм:

1. Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

"2018елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юллау белән килешәсезме:

- Никольский, Пятидворка, Лесные Моркваши, Покровка авылларында урамнарны яктырту буенча чаралар үткәрү;
- Яр буе Морквашы, Покровка авылларында халыкның тормыш куркынычсызлыгы һәм милкен саклау чараларын тәэмин итү (видеокүзәтү камералары урнаштыру, янгын гидрантлары урнаштыру, янгынга каршы резервуарларны урнаштыру һәм ремонтлау);
- Пустые Моркваши бистәсендә мәктәп маршруты буенча тукталыш павильоны төзелеше;
- Десятидворка ав. суэтем башнясын һәм павильонын ремонтлау;

ӘЙЕ — ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы — И.Х.Гаязов